■ Тәрбия

# ЯШЬ БУЫН НИНДИ?

Энҗе БАСЫЙРОВА,
"Акчарлак" нәшрияты чыгарган китаптан алынды

Җәмгыятьнең киләчәге балалар, яшьләр кулында. Ләкин, ни кызганыч, бүген әлеге буын черек. Чөнки тирә-мохиттә бозыклык, азгынлык хакимлек итә. Замана таләбе булган интернет, телевизор аның ярдәмчесе ролен үти. Баланы тәүфыйклы, әдәпле, инсафлы итеп ничек тәрбияләргә, аны бозыклыктан нинди юллар белән саклап калырга?

***- Диндә балаларга җенси тәрбия бирү ничек чагыла һәм ул кайчан башланырга тиеш?***

- Ислам динендә тәрбия иң зур урыннарының берсен алып тора. Ул кыз белән егет берберсен танып йөргәндә үк башлана. Пәйгамбәребез: "Балаларыгыз ир бала булса - әнисенең бертуган абыйсына, кыз бала икән - әтисенең бертуган апасына охшарга мөмкин", - ди. Кыз белән егет өйләнешкәндә, абый-апаларының нindирәк холыклы, тәрбиялеме икәнен күрергә була. Шуңа да ата-ана баласын башлы-күзле иткәндә, нәселләре нинди, анда кемнәр бар - шуны карарга тиеш. Берсендә миңа мондый хәл белән очрашырга туры килде: Америкада яшәүче татарлар бездә яшәүче егеткә кызларын бирергә ризалашмады. Кызның әти-әнисе егетнең нәсел җебен тикшерергә махсус кайтты. Туганнары арасында авыру кеше барын белгәч, кызларын кияүгә бирмәячәкләрен әйттеләр. Бу - чын мөселман йоласы буенча өйләндерү дигән сүз. Без дә шуңа игътибар итәргә тиеш. Ә кызның буйсыны, егетнең гәүдәсе әһәмиятле түгел.

Икенчедән, диндә "карын тәрбиясе" дигән төшенчә дә бар. Әгәр дә булачак әни күбрәк Коръән укыса, намазын калдырмаса, вәгазьләр тыңласа, хәләл ризык белән тукланса, өен оятсыз сүзләрдән сакласа, начар, куркыныч әйберләр карамаса, карынындагы бала тәрбияләнә. Аллаһы Тәгалә: "Сабый тугач ике ел имезегез", - ди. Галимнәр дә ни өчен ике ел имезергә кирәген өйрәнгән. Ике яшькә кадәр 80 процент тәрбияне бала ана сөтеннән ала. Калган 20 процент тәрбия балага уеннар һәм күнегүләрдән бирелә. Димәк, нинди ана - шундый сөт; нинди ризык - шундый сөт. Күп нәрсә ананың ризыгы, холкы һәм халәтенә бәйләнгән. Кызганыч, күп вакыт әлеге мөселман йолалары үтәлмәү аркасында гаиләләр таркала, балалар ятим кала.

***- Балага ике яшь тулгач, тәрбияләүне ничек дәвам итәргә?***

- Ике яшьтән соң сабый күнегүләр, сүзләр тәрбиясенә килеп җитә. Бу җиде яшькә кадәр бара. Шушы вакыт эчендә төрле кыйссалар, пәйгамбәрләрнең риваятьләрен, Коръәндәге хикмәтле хикәяләр белән баланың күңеленә Аллаһы Тәгаләгә мәхәббәт салырга кирәк. Җенси тәрбиянең нигезендә дә Аллаһы Тәгаләгә мәхәббәт торырга тиеш. Бүген җырларның, шигырьләрнең 80-90 проценты мәхәббәткә багышланган. Хәтта: "Мәхәббәтсез тормыш юк", - диләр. Әмма ул кайчак челпәрәмә килә, юкка чыга. Ни өчен соң без мәхәббәт белән бәйле күп гамәлләрдә ялгышабыз, саташабыз? Ник соң яраткан кешебез хыянәт итә яки бу адымга үзебез барабыз? Чөнки без иң әүвәл Аллаһы Тәгаләне яратырга дип тәрбияләнмәгән. Адәм баласы кечкенәдән Аллаһы Тәгаләне күзе белән күрмәсә дә, ул Аны яратып үсәргә тиеш. "Бу гамәлеңне эшләмә, Аллаһы Тәгалә яратмый. Бу - гөнаһ, монысы - изгелек", - диюләр баланың күңеленә кереп кала, тәрбиянең нигезе була. Сабый үзенә юлны да, хатынны да, ирне дә, дусны да Аллаһы Тәгаләгә булган мәхәббәттән чыгып сайлый. Әгәр кешенең күңелендә Аллаһтан курку, Аңа мәхәббәт булмаса, бүген яшьләрне дә, олыларны да җинаятьтән, зинадан, наркотиктан, хәмердән, урлаудан һәм башка төрле чирләрдән бернәрсә дә коткарып кала алмый. Җенси тәрбиянең нигезендә дә Аллаһы Тәгаләгә мәхәббәт торырга тиеш. Ләкин аны балага сендерү өчен ата-ананың үзенең тәрбияле булуы зарур. Сабыйга күпме генә сөйлә, аңлат, тормышта шуның киресен күрсәтсәң, үгет-нәсыйхәтнең нәтиҗәсе калмый.



***- Җенси тәрбия турында пәйгамбәребез нәрсә ди?***

- Гаиләдә кыз бала да, ир бала да бар икән, Пәйгамбәребез аларны җиде яшьтән соң бергә яткырмаска куша. Җиде яшьтән соң балалар әти-әнисе бүлмәсенә рөхсәт сорап керергә тиеш. Балага гигиена кагыйдәләрен өйрәтергә кирәк.

Ислам динендә кызлар белән егетләр аерым дәрес ала. Психологиядә нивелирование дигән термин бар. Бүген күп мәктәпләрдә укытучылар - хатын-кызлар. Ир бала җиде яшьтән унҗидесе тулганчы хатын-кыз тәрбиясендә үсә. Сыйныф җитәкчесе ролен институт тәмамлап кайткан яшь кыз үти. Бу вакытта аның үзенең дә әдәп-әхлагы башкаларга җиткерерлек булмый. шуңа да холкы ир балаларга йога. Егетләр кызларга охшый башлый. Бүген кайбер егетләрнең йөрешләре, туктамыйча көлүләре, сөйләшү манералары - моның ачык мисалы. Укытучы ир кеше булса, ул ирләрчә сөйләшәчәк, ир балаларга ирләр тәрбиясе бирәчәк.

Кызлар белән егетләрнең бергә укуларының тагын бер тискәре ягы: кызлар егетләргә караганда тизрәк өлгерә. Бу вакытта егетләргә кызлардан зур тәэсир бара. Аларның егетлек фикерләре зәгыйфьләнә.

Өйдә әти белән әни арасында татулык булмаса, бала әтисез яки әнисез үссә, бала хатын-кызның кем дә, ирнең кем икәнен һәм гаиләдә ничек мөгамәлә урнаштырасын белми. Әнисе тәрбиясендә генә үскән кыз кияүгә чыккач, гаиләне алып барырга тырыша, әмма үрнәк юклыктан югалып калырга мөмкин. "Кешенең хыялы чикләнгән", - диләр. Мәсәлән, җәннәтне ясарга кушсалар, ясый алмаячакбыз. Шуның кебек, егет әнисе белән генә үссә, әтинең нәрсә икәнен белми.

Ләкин әти-әни була торып та, кайчак аларның урыннары алышына. Бу шулай ук проблема тудыра. Кыз бала җитәкче, ир бала буйсынучы ролендә тәрбияләнә. Әти белән әни бала каршында спектакль уйный. Тамаша нинди булса, бала шулай үсә.

***- Җенси тәрбия турында әңгәмәләрне ничә яшьтән алып барырга кирәк?***

- Баланың сораулары туарга тиеш. Диндә кешене көчләп өндәргә ярамый, аның сораулары тууы хәерлерәк. Пәйгамбәребез җиде яшьтән балаларга намаз өйрәтергә куша. Ун яшьтән инде алар биш вакыт намазны төгәл үтәргә тиеш. Җенси тәрбия Ислам динендә киң таралмаган, бөтен нечкәлекләре белән бирелмәгән. Әмма кирәк кадәр аңлатылып кителә. Иң мөһиме - ир-ат белән хатын-кызның аермасы, алардагы үзенчәлекләр, бер-берсенә кирәк булулары, файдалары. Хатын-кызга ана һәм ир кешенең хатыны буларак бәя бирелә. Кызганыч, бүген "Матурлык конкурсы" дип хатын-кызны чишендерәләр. Бу хатын-кыз шундый буйда, шундый билле һәм шундый чәчле булырга тиеш дигән сүзме? Шуннан соң ирләр үз хатыннарына карагач: "Ул мондый түгел", - дип уйлый, урамнан шундый зат эзли башлый. Кайда эчке матурлык? Кайда сигезәр баланы аякка бастырган ялгыз әниләр? Без эчке гүзәллекне югалттык түгелме? Ислам дине балаларның эчке дөньясын тәрбияли.

***- Хәзер балалар бозыклыкка интернет, телевизордан өйрәнә дибез. Бала әлеге мәгълүмат чараларын файдага куллансын өчен нишләргә?***

- Антон Чеховның: "Если подлецу дать гениальное, получается гениальный подлец", - дигән сүзе бар. Эчендә юньсезлек булса, кеше шуны куллана. Баланың да күңелендә бозыклык булса, Интернетта да шундый сайтлар гына эзләячәк. Эчендә тәрбия икән, ул аннан сорауларына җавап таба, белемен арттыра. Һәрнәрсә ике яклы. Әйтик, авыздагы тел белән сүгенергә, гайбәт сатып, гөнаһлы булырга, изге сүз әйтеп кешене терелтергә һәм дога кылырга мөмкин. Бер үк күз белән Коръән укырга яки әшәкелек карарга була. Корьәндә Аллаһы Тәгалә: "Мин һәрнәсәне ике яклы итеп яраттым", - ди. Кеше ак ягын сайлыймы, карасынмы, аның ирегендә. Машина руленә утырткaнчы, укып, таныклык алырга кирәк булган кебек, балага интернет тоттырганчы да нәрсә өчен бирәсең, шуны ачыклап бетерү шарт.

***- Баланы күзәтү зарурмы?***

- Баланы күзәтеп бетерә алмыйсың. Күзәткән саен ул аскарак төшә. Коръәндә Аллаһы Тәгалә: "Кешене артыннан тикшереп йөрмәгез", дип әйтә. Иреңнең кесәсеннән запискаларны һәм телефонындагы смс-хәбәрләрне уку эш түгел. Кем язганын белерсең. Ләкин ни өчен икәненә барыбер төшенә алмассың. Гаеп атта да, тәртәдә дә бар. Икесенә дә карарга кирәк. Балаңа, ireңә яки хатыныңа ышанмаска ниндидер сигнал булды икән, бу үзеңә дә хәбәр килде дигән сүз. Димәк, син аларга тиешле игътибар бирмәгәнсең. Син гаиләңне ашатырга, эчертергә дип йөргәнсең, тиешле тәрбия турында оныткансың.

***- Әти-әни баланы ничә яшькә кадәр тәрбияли ала?***

- 12 яшькә кадәр бала тәрбияләнә, Аннан соң аңа физиологик яктан да, психологик планда да йогынты ясап булмый. 12 яшьтән соң мәгълүмат биреп, юл күрсәтергә генә мөмкин. 3 яшьтән соң исә холык та үзгәрми.

***- Ислам динендә балага җәза бирергә рөхсәт ителәме?***

- Ителә, ләкин чама хисен онытмыйча һәм нәрсә өчен икәнен төгәл белеп. Аллаһы Тәгалә кеше гөнаһ кылгач башына сукмый. Ә тәүбә итәргә вакыт калдыра. Акыллы кеше мөмкинлектән файдалана.

## Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Зөлхизә - Мөхәррәм 2013 миләди йыл**
**1434 һижри йыл.**

| Зөлхиҙә, Мөхәррәм | Аҙна көндәре | Октябрь, ноябрь | Иртәнге намаҙ | Ҡояш сыға | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 11 | Шаршамбы | 16 | 7.19 | 8.49 | 14.30 | 17.43 | 19.13 | 20.43 |
| 12 | Кесе йома | 17 | 7.21 | 8.51 | 14.30 | 17.41 | 19.11 | 20.41 |
| 13 | Йома | 18 | 7.23 | 8.53 | 14.30 | 17.38 | 19.08 | 20.38 |
| 14 | Шәмбе | 19 | 7.25 | 8.55 | 14.30 | 17.36 | 19.06 | 20.36 |
| 15 | Йәкшәмбе | 20 | 7.27 | 8.57 | 14.30 | 17.34 | 19.04 | 20.34 |
| 16 | Дүшәмбе | 21 | 7.29 | 8.59 | 14.30 | 17.31 | 19.01 | 20.31 |
| 17 | Шишәмбе | 22 | 7.31 | 9.01 | 14.30 | 17.29 | 18.59 | 20.29 |
| 18 | Шаршамбы | 23 | 7.33 | 9.03 | 14.30 | 17.27 | 18.57 | 20.27 |
| 19 | Кесе йома | 24 | 7.35 | 9.05 | 14.30 | 17.25 | 18.55 | 20.25 |
| 20 | Йома | 25 | 7.37 | 9.07 | 14.30 | 17.22 | 18.52 | 20.22 |
| 21 | Шәмбе | 26 | 7.39 | 9.09 | 14.30 | 17.20 | 18.50 | 20.20 |
| 22 | Йәкшәмбе | 27 | 7.41 | 9.11 | 14.30 | 17.18 | 18.48 | 20.18 |
| 23 | Дүшәмбе | 28 | 7.43 | 9.13 | 14.30 | 17.16 | 18.46 | 20.16 |
| 24 | Шишәмбе | 29 | 7.45 | 9.15 | 14.30 | 17.14 | 18.44 | 20.14 |
| 25 | Шаршамбы | 30 | 7.47 | 9.17 | 14.30 | 17.11 | 18.41 | 20.11 |
| 26 | Кесе йома | 31 | 7.49 | 9.19 | 14.30 | 17.09 | 18.39 | 20.09 |
| 27 | Йома | 1 | 7.51 | 9.21 | 14.30 | 17.07 | 18.37 | 20.07 |
| 28 | Шәмбе | 2 | 7.53 | 9.23 | 14.30 | 17.05 | 18.35 | 20.05 |
| 29 | Йәкшәмбе | 3 | 7.55 | 9.25 | 14.30 | 17.03 | 18.33 | 20.03 |
| 1 | Дүшәмбе | 4 | 7.57 | 9.27 | 14.30 | 17.01 | 18.31 | 20:01 |
| 2 | Шишәмбе | 5 | 7.59 | 9.29 | 14.30 | 16.59 | 18.29 | 19:59 |
| 3 | Шаршамбы | 6 | 8.01 | 9.31 | 14.30 | 16.57 | 18.27 | 19:57 |
| 4 | Кесе йома | 7 | 8.03 | 9.33 | 14.30 | 16.55 | 18.25 | 19:55 |
| 5 | Йома | 8 | 8.05 | 9.35 | 14.30 | 16.53 | 18.23 | 19:53 |
| 6 | Шәмбе | 9 | 8.07 | 9.37 | 14.30 | 16.51 | 18.21 | 19:51 |
| 7 | Йәкшәмбе | 10 | 8.09 | 9.39 | 14.30 | 16.49 | 18.19 | 19:49 |
| 8 | Дүшәмбе | 11 | 8.11 | 9.41 | 14.30 | 16.48 | 18.18 | 19:48 |
| 9 | Шишәмбе | 12 | 8.13 | 9.43 | 14.30 | 16.46 | 18.16 | 19:46 |
| 10 | Шаршамбы | 13 | 8.15 | 9.45 | 14.30 | 16.44 | 18.14 | 19:44 |
| 11 | Кесе йома | 14 | 8.17 | 9.47 | 14.30 | 16.43 | 18.13 | 19:43 |
| 12 | Йома | 15 | 8.19 | 9.49 | 14.30 | 16.41 | 18.11 | 19:41 |